**Түбән Көек төп гомумибелем бирү мәктәбенең эти-әниләр комитетының визиткасы.**

Әти-әниләр сәхнәгә чыга.

1әни. Танышлармы, таныш түгелләрме,

Берәүме сез, икәү, өчәүме?

Дус яшәүгә җирдә нәрсә җитә,

2 әни. Таныш булыйк, әйдә, исәнмесез!

Ком җылысын тойган кара тәнме,

Кар салкынын тойган ак тәнме сез?

Йөрәгебез безнең берүк төсле,

Таныш булыйк, әйдә, исәнмесез!

3 әни. Хәерле көн, кадерле дуслар! Сезне чал тарихлы Әтнә районы Түбән Көек төп гомумибелем бирү мәктәбенең 6 сыйныф укучылары һәм аларның эти-әниләре сәламли.

4 әни. Ә ни өчен менә нәкъ 6 сыйныф дисезме? Чөнки алар иң тату, иң бердәм сыйныф. Укуда да, спортта да алар алдынгылыкны бирмиләр. Мәктәп һәм район күләмендә уздырылган төрле ярышларда алар һәрвакыт теләп катнашалар һәм зур җиңүләргә дә ирешәләр.

1 эни. Ә без шул укучыларның эти-әниләр комитеты вәкилләре.

2 эни. Ә нәрсә соң ул эти-әниләр комитеты дисезме?

3 эни. Әти-әниләр комитеты ул балалар белән бергә мәктәп тормышында кайнаучы, укытучылар коллективына һәрвакыт ярдәмгә әзер торучы зур бер тату гаилә!

Безнең исем: “Бердәмлек”

Безнең девиз: “Дус, тату эшлик эшне,

Без дуслык белән көчле!”

4 әни. Чал тарихлы Әтнәдән

Ялкынлы кайнар сәлам!

Ял иткәндә чәй эчәрсез

Әтнә чәкчәге белән!

1 әни.Мәктәп белән бер сулышта яшәгәнгә күрә, безнең балалар тырыш, бердәм һәм һәрвакыт зур уңышларга ирешәләр дә.

2 әни. Әйдәгез, хәзер сүзне балаларның үзләренә бирик.